## КЕРЕШ СҮЗ

Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында тармак терминнары сүзлекләре төзеп бастыруның күптәннән килгән традициясе бар. Соңгы елларда гына да төрле авторлар тарафыннан төзелгән «Инглизчә-русча-татарча компьютер терминнары сүзлеге» (2015), «Лингвистик терминнарның русча-татарча аңлатмалы сүзлеге» (2016), «Татарча-русча хәрби лексика сүзлеге» (2017), «Татарча-русча тукучылык һәм тегүчелек атамалары сүзлеге» (2018), «Татарча-русча-латинча кош атамалары сүзлеге» (2018), «Балык атамаларының татарча-русча-латинча аңлатмалы сүзлеге» (2019), «Үсемлек атамаларының татарча-русча аңлатмалы сүзлеге» (2020) кебек хезмәтләр дөнья күрде. «Русча-татарча геодезия терминнары сүзлеге» дә шул юнәлештәге эшнең дәвамы буларак төзелде.

Һәр телдә терминнар даими ясалып һәм үзгәреп тора. Аларның дөрес кулланылышын һәм бердәйлеген саклау максаты белән махсус сүзлекләр төзелә. Тәкъдим ителә торган сүзлектә геодезиянең төрле тармакларына (югары геодезия, гамәли геодезия, картографиягә) караган берәмлекләр, шулай ук геодезия белән чиктәш фән һәм техника (астрономия, гравиметрия һ. б. ш.) өлкәсендәге кайбер терминнар теркәлде.

Картография терминологиясенә аерым игътибар ителде. Киң кулланышта йөргән кайбер картографик кыскартылмалар да тәрҗемә итеп бирелде.

Хезмәт киң катлау укучыларга, аерым алганда, техник уку йортлары студентлары һәм укытучылары, тәрҗемәчеләр, журналистлар өчен гамәли кулланма буларак тәкъдим ителә.

Сүзлек Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбия һәм сәнгать институтының лексикография бүлегендә төзелде. Эш күләме түбәндәгечә бүленде: сүзлекнең А – З хәрефләренә караган өлешен И. И. Сабитова, Й – Н өлешен –

Э. И. Сафина, О – Р өлешен – О. Н. Галимова, С – Я өлешен – Ф. И. Таһирова төзеде. Томны тулысынча Р. Т. Сәфәров редакцияләде.

Сүзлекнең эшләнешенә, эчтәлегенә бәйле фикер һәм теләк-тәкъдимнәрегезне түбәндәге адреска юллый аласыз:

420111, Казан шәһ., К. Маркс ур., 12/4 йорт

ТР ФА Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият

һәм сәнгать институты.

Электрон адрес: iyali.anrt@mail.ru.